ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2016 елның 25 апреле**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1082**

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районында 2016-2020 елларга
Наркотикларга каршы программаны раслау
турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында 2016-2020 елларга Наркотикларга каршы программаны әлеге карар кушымтасы нигезендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштыруны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 апрелендәге 1082 номерлы карарына
Кушымта

**Татарстан Республикасы**

**Зеленодольск муниципаль районының**

**2016 - 2020 елларга**

# Наркотикларга каршы программасы

**Зеленодольск муниципаль районында 2016-2020 елларга Наркотикларга каршы программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Зеленодольск муниципаль районында 2016-2020 елларга наркотикларга каршы программа (алга таба - Программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның координаторы | Наркотиклар әйләнешен тикшереп тору буенча Россия Федерациясе Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Зеленодольск районара бүлеге |
| Программаның төп эшләүчеләре | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту буенча Россия Федерациясе Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Зеленодольск районара бүлеге;<br>«Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ<br>Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе»;<br>Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе;<br>Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;<br>Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районындагы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге |
| Программаның максаты | 2020 елга Зеленодольск муниципаль районында наркотикларны законсыз тарату һәм медицина булмаган наркотиклар куллану дәрәҗәсенең кимүе |
| Программаның бурычлары | наркотик чараларның законсыз әйләнеше өлкәсендә хокук саклау органнарының көчләрен активлаштыру;<br>бәйле булганнарны дәвалау һәм реабилитацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру;<br>балалар һәм яшьләр санын кызыксынулар буенча өстәмә белем бирү өлкәсенә җәлеп итү; |

| | |
|---|---|
| | яшүсмерләр клубларының һәм медицина-социаль хезмәтләрнең матди-техник базасын камилләштерү;<br>халыкта сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2016-2020 еллар |
| Программаны финанслау кләмнәре һәм чыганаклары | Республикасы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау буенча программа чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан финанс чаралары бүлеп бирү зарур |
| Гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | Программа чараларын гамәлгә ашыру 2020 елга 2015 елга карата түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>тикшерүче авыр һәм аеруча авыр наркоҗинаятьләр санын арттыруны тәэмин итү;<br>наркотикларга бәйле дәвалanучыларның саны арту һәм аларны реабилитацияләү;<br>мәнфәгатьләр, физик культура һәм спорт буенча түгәрәкләрдә даими рәвештә шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр санын арттыру;<br>сәламәт яшәү рәвешенә юнәлдерелгән балалар һәм яшьләр санын арттыру |

## I. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның максаты - 2020 елга, 2015 елга карата Зеленодольск муниципаль районында наркотикларны законсыз тарату һәм медицина булмаган наркотикларны законсыз куллану масштабларын киметү.

Программаның максатына ирешү түбәндәге юнәлешләр буенча чараларны балансылы яраштыру нигезендә гамәлгә ашырыла:

а) республика эчендә наркотикларны ташу һәм таратуны легаль булмаган җитештерү инфраструктурасын юкка чыгару юлы белән наркотиклар тәкъдимен киметү, наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары, шулай ук көчле тәэсир итүче легаль матдәләрне законсыз әйләнешкә керүгә юл куймау, наркотикларның яңа төрләре, шулай ук медицина куллануы өчен булмаган контрольсез психоактив матдәләр һәм чаралар әйләнешенә чик кую;

б) профилактик, дәвалау һәм реабилитация эше системасын камилләштерү, җәмгыятьтә медицина өчен булмаган наркотикларны куллануга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру юлы белән наркотикларга ихтыяҗны киметү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк;

- наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча хокук саклау органнарының көчләрен активлаштыру;
- дәвалау һәм тернәкләндерү ярдәме системасын камилләштерү;
- балаларны һәм яшьләрне үз мәнфәгатьләре, физик культура һәм спорт түгәрәкләрендә системалы дәресләргә җәлеп итү өчен шартлар тудыру;

-халыкта наркотиклар куллануга карата тискәре мөнәсәбәт һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивация формалаштыру.

Медицина өчен булмаган наркотикларны кулلануны профилактикалау системасын формалаштыруда Зеленодольск муниципаль районының барлык дәрәҗәдәге дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалар, гражданнар, шул исәптән мәгариф, медицина һәм мәдәни-агарту учреждениеләре белгечләре, яшьләр оешмалары волонтерлары катнаша.

Медицина өчен булмаган наркотикларны куллануны профилактикалау чаралары халыкның барлык категорияләре өчен, беренче чиратта, начар гаилә, социаль шартларда, авыр тормыш шартларында булган балалар һәм яшьләр, шулай ук медицина өчен булмаган наркотикларны куллану куркынычы янаган затлар өчен билгеләнгән.

2020 елда күрсәтелгән бурычларны үтәүнең максатчан күрсәткечләре (индикаторлары) 2015 ел дәрәҗәсенә карата түбәндәгеләр;

- тикшерелгән авыр һәм аеруча авыр наркотик җинаятьләр санының үсешен тәэмин итү;

- дәвалану һәм тернәкләндерү узган наркомания белән авыручылар санын арттыруны тәэмин итү;

- мәнфәгатьләр, физик культура һәм спорт буенча түгәрәкләрдә даими рәвештә шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр санын арттыру;

- сәламәт яшәү рәвешенә юнәлдерелгән балалар һәм яшьләр санын арттыру.

Наркотикларның таралуына каршы тору рәвешләрен һәм методларын даими камилләштерү зарурилыгы аркасында, шулай ук программада озак вакытлы чараларның шактый микъдарын исәпкә алып, аны тормышка ашыру 5 еллык чорга (2016-2020 елларга кадәр) исәпләнгән һәм бер этапка гамәлгә ашырыла.

Программаны эшләгәндә Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 9 июнендәге 690 номерлы Указы белән расланган 2020 елга кадәр Россия Федерациясе дәүләт наркотикларга каршы сәясәте стратегиясенең төп нигезләмәләре, башка регионнарның наркотиклар һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору тәҗрибәсе, министрлыклар һәм ведомстволар, җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре исәпкә алынды.

Программа 2009 елның 29 октябрендәге 50 номерлы «Наркомания һәм токсикомания профилактикасы турында» Татарстан Республикасы Законы, 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында җинаятьчелеккә каршы тору җәмәгать тәртибен тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнде.

## II. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Әлеге программаны тормышка ашыру белән бәйле чараларны финанслау тиешле финанс елына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында тиешле максатларга каралган ассигнованиеләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

| | 2016 (сумнарда) | 2017 (сумнарда) | 2018 (сумнарда) | 2019 (сумнарда) | 2020 (сумнарда) |
|---|---|---|---|---|---|
| Җирле бюджет | 500 000 | 500 000 | 500 000 | 500 000 | 500 000 |
| Барлыгы | 500 000 | 500 000 | 500 000 | 500 000 | 500 000 |

## III. Программаны гамәлгә ашыру механизмы һәм аның үтәлешен тикшереп тору

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Зеленодольск муниципаль районы наркотикларга каршы комиссия белән килешенеп, программаның үтәлешен гомуми контрольдә тота, максатчан күрсәткечләрне һәм программа чаралары буенча чыгымнарны, программаны тормышка ашыру механизмын, башкаручылар составын төгәлли.

Программаны үтәүчеләр программа чараларын гамәлгә ашырганнан соң Наркомания комиссия сәркатибенә билгеләнгән формада чаралар үтәлеше турында квартал саен хисап бирәләр.

Зеленодольск муниципаль районының 2016-2020 елларга
наркотикларга каршы программага
Кушымта

**Программалы чаралар һәм аларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары исемлеге**

| № т/б | Чараның атамасы | Башкару вакыты | Финанслау чыганаклары | Еллар буенча финанс белән тәэмин итү (мең сумнарда) | | | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | |
| **1 Наркоманияне профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча оештыру чарасы** | | | | | | | | | |
| 1.1 | Зеленодольск муниципаль районында нарковәзгыятьне характерлаучы мәгълүматлар җыюны һәм анализлауны гамәлгә ашырырга | 2016-2020 | МБ | 10.000 | 10.000 | 10.000 | 10.000 | 10.000 | ЗМР Башкарма комитеты |
| 1.2 | Наркоманияне профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча авторлык программалары бәйгеләрен оештырырга һәм үткәрергә. | 2016-2020 | МБ | 10.000 | 10.000 | 10.000 | 10.000 | 10.000 | Программада катнашучыларның барысы да |
| 1.3 | Наркотиклар, алкоголизм һәм тәмәке тартуны куллануны профилактикалау һәм кисәтү максатында барлык типтагы һәм төрдәге белем бирү учреждениеләрендә, социаль приютларда укучылар өчен семинарлар, лекцияләр оештырырга һәм үткәрергә | 2016-2020 | МБ | 10.000 | 10.000 | 10.000 | 10.000 | 10.000 | Программада катнашучыларның барысы да |
| 1.4 | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлтелгән массакүләм чаралар уздыруны оештырырга. | 2016-2020 | МБ | 25.000 | 25.000 | 25.000 | 25.000 | 25.000 | Программада катнашучыларның барысы да |
| 1.5 | Мәгариф учреждениеләре | 2016-2020 | МБ | 20.000 | 20.000 | 20.000 | 20.000 | 20.000 | ЗМР Башкарма комитетының |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | арасында иҗади һәм спорт-савыктыру конкурслары уздыруны оештырырга | | | | | | | | мәгариф идарәсе |
| 1.6 | Район һәм шәһәр спорт чараларын оештыру һәм үткәрү | 2016-2020 | МБ | 200.000 | 200.000 | 200.000 | 200.000 | 200.000 | ЗМР Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;<br>ЗМР Башкарма комитетының мәдәният идарәсе |
| 1.7 | ЗМР яшьләр сәясәтен үстерү буенча район һәм шәһәр чараларын оештыру һәм үткәрү | 2016-2020 | МБ | 100.000 | 100.000 | 100.000 | 100.000 | 100.000 | ЗМР Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе; |
| 1.8 | Профилактик чараларны оештыру һәм үткәрү:<br>-«Зимняя эстрада» вокаль конкурсы<br>- «Здоровье forever» яшьләр акциясе<br>-"Брейк сәламәтлек территориясе" брейк-данс буенча республика фестивале | 2016-2020<br>Февраль<br>Май<br>Июнь | МБ<br>МБ<br>МБ | 10.000<br>5.000<br>5.000 | 10.000<br>5.000<br>5.000 | 10.000<br>5.000<br>5.000 | 10.000<br>5.000<br>5.000 | 10.000<br>5.000<br>5.000 | ЗМР Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;<br>ЗМР Башкарма комитетының мәдәният идарәсе |
| 1.9 | Халыкның төрле төркемнәре арасында наркотикларга каршы иҗади һәм спорт - савыктыру конкурслары уздыруны оештырырга:<br>«Авто - paty» машина йөртүчеләр конкурсы<br>- "Югарырак, көчлерәк, тизрәк" яшүсмерләр өчен күңелле стартлар<br>-«Сәламәт булыйк» 5-7 | 2016-2020<br>июнь декабрь<br>февраль | МБ<br>МБ | 3.000<br>2.000 | 3.000<br>2.000 | 3.000<br>2.000 | 3.000<br>2.000 | 3.000<br>2.000 | ЗМР Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;<br>ЗМР Башкарма комитетының мәдәният идарәсе |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | сыйныфлар өчен күңелле стартлар | | | | | | | | |
| 1.10 | ҮКЧ китапханәләрендә наркоманияне профилактикалау мәсьәләләре буенча тематик әдәбият күргәзмәләрен оештырырга:<br>-31 май - Бөтендөнья тәмәкесез көн<br>-26 июнь - Халыкара наркоманиягә каршы көрәш көне<br>-19 ноябрь - Халыкара тәмәкесез көн<br>-1 декабрь - СПИДка каршы Халыкара көрәш көне | 2016-2020 | МБ | 3.000 | 3.000 | 3.000 | 3.000 | 3.000 | ЗМР Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе;<br>Үзәк китапханә челтәре |
| | **Кадрларны әзерләү һәм тәҗрибә алмашу** | | | | | | | | |
| 2.1 | Халыкны наркотикларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча халыкара һәм регионара хезмәттәшлекне үстерергә. | Программаны тормышка ашыру кысаларында | МБ | 10.000 | 10.000 | 10.000 | 10.000 | 10.000 | Программаның барлык катнашучылары |
| 2.2 | Наркотикларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча белгечләр әзерләүне оештырырга | 2016-2020 | МБ | 2.000 | 2.000 | 2.000 | 2.000 | 2.000 | ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе |
| 2.3 | Халыкны наркотикларны профилактикалау, наркобәйлелекне дәвалау һәм реабилитацияләү мәсьәләләре буенча Россия һәм республика галимнәрен җәлеп итеп, белгечләрнең квалификациясен | | МБ | 30.000 | 30.000 | 30.000 | 30.000 | 30.00 | Программаның барлык катнашучылары |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | күтәрү курсларын оештырырга | | | | | | | | |
| **3 Мәгълүмат һәм фәнни-методик тәэмин итү** | | | | | | | | | |
| 3.1 | ҮКЧ китапханәләре өчен наркотикларга каршы юнәлештәге әдәбиятны сатып алырга һәм таратырга | 2016-2020 | МБ | 5.000 | 5.000 | 5.000 | 5.000 | 5.000 | Үзәк китапханә челтәре |
| 3.2 | "Хәвеф-хәтәр төркеменнән" балаларның мәгълүматлары базасын вакытында яңарту | | МБ | 3.000 | 3.000 | 3.000 | 3.000 | 3.000 | ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;<br>ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск районындагы социаль яклау бүлеге;<br>ЗМР Башкарма комитеты каршындагы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе |
| 3.3 | Наркотикларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча дифференциацияләнгән укыту программаларын кертергә | 2016-2020 ел | МБ | 2.000 | 2.000 | 2.000 | 2.000 | 2.000 | ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе |
| 3.4 | Наркотикларны профилактикалау буенча программаларны гамәлгә ашыручы психолог-социаль үзәкләр челтәрен үстерүне тәэмин итәргә | 2016-2020 | МБ | 5.000 | 5.000 | 5.000 | 5.000 | 5.000 | ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;<br>ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск районындагы социаль яклау бүлеге |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.5 | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә волонтерлык хәрәкәтен үстерүдә ярдәм итү чаралары комплексын эшләргә һәм гамәлгә ашырырга | 2016-2020 | МБ | 20.000 | 20.000 | 20.000 | 20.000 | 20.000 | ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;<br>ЗМР Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе |
| **Аерым категориядәге затларга карата хокук бозуларны профилактикалау** | | | | | | | | | |
| 4.1 | Балаларның ялын оештыру өчен өстәмә белем бирү учреждениеләрен үстерүне тәэмин итәргә | 2016-2020 | МБ | 5.000 | 5.000 | 5.000 | 5.000 | 5.000 | ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;<br>ЗМР Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;<br>ЗМР Башкарма комитетының мәдәният идарәсе |
| 4.2 | Күзәтүчесезлекне, хокук бозуларны кисәтүгә һәм хокук бозучылар белән индивидуаль тәрбия эшен яхшыртуга, җинаятьчелеккә китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклауга юнәлдерелгән "Яшүсмер", "Мәктәп" ведомствоара операцияләрен үткәрергә | 2016-2020 | МБ | 7.000 | 7.000 | 7.000 | 7.000 | .000 | ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;<br>ЗМР Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе; |
| 4.3 | Балаларның ата-аналары, балалар бакчасы һәм белем бирү учрежденияләре укучылары белән наркотикларга каршы эшне профилактикалау программасын кертергә.<br>"Уңышка юл", "Кара төстән башка, барлык төсләр". | 2016-2020 | МБ | 3.000 | 3.000 | 3.000 | 3.000 | 3.000 | ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе |
| **5 Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эш** | | | | | | | | | |
| 5.1 | Наркотиклар куллануга һәм район массакүләм мәгълүмат чараларында сәламәт яшәү | 2016-2020 | МБ | 5.000 | 5.000 | 5.000 | 5.000 | 5.000 | Программада катнашучыларның барысы да |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | рәвешен пропагандалауга каршы юнәлдерелгән иҗтимагый фикер формалаштырырга | | | | | | | | |
| 5.2 | Зеленодольск муниципаль районы сайтында мәгълүмат урнаштыру | 2016-2020 | | - | - | - | - | - | ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;<br>ЗМР Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;<br>ЗМР Башкарма комитетының мәдәният идарәсе |